Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
«Иске Гришкин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге гражданнары җыены карары

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкин авыл җирлеге составына керүче Илькино авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2022 елның 3 декабрьдән № 3

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкин авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкин авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 115 номерлы карары нигезендә Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкин авыл җирлегенең Илькино авылында 2022 елның 3 декабрендә 11 сәг.00 минутта узган гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде. 2023 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкин авыл җирлегенең Илькино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 15000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны Илькино авылында түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Юраш елгасы аша Илкә авылы зиратына күперчек салу.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә ярашлы рәвештә, сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 2 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучылар саны 2.

гражданнар җыены этапларында «Риза» дип биргән тавышларның гомуми саны-2;

"Каршы" дип биргән тавышларының гомуми саны -0

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнары җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкин авыл җирлегенен Илькино гражданнары җыенын узган дип таныргa, җыен нәтиҗәләре дөрес дип санарга.
2. “2023 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкин авыл җирлегенең Илькино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 15000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм Илькино авылындагы түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешәсезме?” дигән сорау буенча карар кабул итәргә:
   - Юрашка елгасы аша Илькино зиратына күпер салу
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Иске Гришкин авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru .
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Иске Гришкин авыл җирлеге башлыгы В.В.Мамакова